ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2023 г. Заинск № 773

**«Интернет мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс уздыру турында хәбәрнамә урнаштыру тәртибен раслау хакында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты

**карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс уздыру турында мәгълүматны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Район Башкарма комитеты җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

юрист

Г.Х.Никифорова
8(85558)3 07 19

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
202_ елның «02» 10 чыккан
773 номерлы карарына
кушымта.

**Интернет мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Зәй муниципаль районы территриясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс уздыру турында хәбәрнамә урнаштыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуларның муниципаль маршруты буенча һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрү турында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә хәбәр итүне урнаштыруның әлеге тәртибе "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законы, "Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими йөртүне оештыруның аерым мәсьәләләре турында" 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнә.

2. Әлеге тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

3. Зәй муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуларның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташуларны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрү турында хәбәр итү Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба-рәсми сайт) муниципаль маршрут буенча ташуларны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрү турында карар кабул ителгән көннән алып 1 эш көне дәвамында урнаштырыла.

4. Ачык конкурс үткәрү турында хәбәр итүгә кертелгән үзгәрешләр, рәсми сайтта ачык конкурс үткәрү турында хәбәр итүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән көннән алып 1 эш көне дәвамында урнаштырыла.

5. Ачык конкурс үткәрү турында хәбәрдә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) ачык конкурс оештыручысының исеме, урнашу урыны, почта адресы һәм электрон почта адресы, контакт телефон номеры;

2) ачык конкурс предметы;

3) конкурс документларын бирү вакыты, урыны һәм тәртибе, конкурс документлары урнаштырылган рәсми сайт;

4) әгәр күрсәтелгән түләү билгеләнгән булса, кәгазьдә конкурс документациясен бирү өчен түләү күләме, тәртибе һәм кертү вакыты;

5) ачык конкурста катнашу өчен гаризалар белән конвертларны ачу урыны, датасы һәм вакыты, шулай ук мондый гаризаларны карау һәм ачык конкурска йомгак ясау урыны һәм датасы.

6. Ачык конкурс үткәрү турында хәбәр итүгә үзгәрешләр кертү турында карар ачык конкурста катнашу өчен гаризалар бирү тәмамланганчы биш көннән дә соңга калмыйча кабул ителә. Ачык конкурс предметын үзгәртү рөхсәт ителми. Ачык конкурс үткәрү турында хәбәр итүгә кертелгән үзгәрешләр ачык конкурсны оештыручының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә ачык конкурсны оештыручы билгеләгән тәртиптә урнаштырыла. Шул ук вакытта ачык конкурста катнашу өчен гаризалар бирү вакыты ачык конкурс уздыру турында хәбәр итүгә кертелгән үзгәрешләр басылып чыккан һәм (яки) урнаштырылган көннән алып, ачык конкурста катнашу өчен гаризалар бирү тәмамланганчыга кадәр (бу срок егерме көннән дә ким булмаска тиеш) кабул ителә.